СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Чехова, д.18, с. Верхний Услон, 422570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

Чехов ур., 18 нче йорт, Югары ослан авылы, 422570

Тел.: (84379) 2-13-38, факс: (84379) 2-18-39. E-mail: sovet.uslon@tatar.ru, verhniy-uslon.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ | КАРАР

13.09.2024 | с. Верхний Услон | № 51-664

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләрнен вакытыннан алда туктату турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясындагы 10 өлешенең 2 пункты, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставының 50 статьясындагы 1 өлешенең 2 пункты нигезендә Варакин Евгений Анатольевичның үз теләге белән отставкага китүе турында гаризасын карап, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасыннан үз теләге белән шәхси гаризасы нигезендә Варакин Евгений Анатольевичны отставкага җибәрергә.
2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Варакин Евгений Анатольевичның вәкаләтләрен 2024 елның 11 сентябреннән вакытыннан алда туктатылган дип санарга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Югары Ослан муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (verhniy-uslon.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Совет рәисе урынбасары,
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы урынбасары С.В. Осянин